ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешендә:

а) 4 пунктка “территориясе чикләрен” сүзләреннән соң “, күрсәтелгән чикләрдә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне” сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $9^2$ пункт өстәргә:

“$9^2$) Федераль законның $34^1$ статьясы нигезендә мәдәни мирас объектын саклау зонасы чикләрен Федераль законның $34^1$ статьясындагы 3 һәм 4 пунктларында каралган ераклыклардан үзгә ераклыкта билгеләү каралган карар кабул итү;”;

2) 11 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Массакүләм репрессияләр корбаннары күмелгән урыннар табылган очракта, Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органына гариза җирле үзидарә органы тарафыннан җибәрелә.”;

3) 16 статьяда:

а) статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“16 статья. **Региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлеген, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең саклау предметын, региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрен, күрсәтелгән чикләрдә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау тәртибе**”;

б) 11 өлештә “һәм региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре” сүзләрен “, региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре, күрсәтелгән чикләрдә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләр” сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ өлеш өстәргә:

“$11^1$. Билгеләнгән тәртиптә расланган региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлеге, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең саклау предметы, региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре, күрсәтелгән чикләрдә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләр, аларны раслау турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, чикләрендә региональ әһәмияттәге тарихи җирлек урнашкан муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органына җибәрелә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон, 2016 елның 3 октябреннән үз көченә керә торган 1 статьяның 1 пунктындагы “б” пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 6 июле
№ 52-ТРЗ